| | |
|---|---|
| ГЛАВА<br>МАЛОМЕМИНСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>КАЙБИЦКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН<br>РЕСПУБЛИКАСЫ<br>КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ<br>КЕЧЕ МӘМИ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>БАШЛЫГЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

10.11.2025ел. Кече Мәми ав. № 3

Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Кайбыч муниципаль районының Имәнле-Бортас торак пунктында гражданнар җыенын билгеләү турында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Кече Мәми авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә КАРАР ИТӘМ:

1. 2025 елның 24 ноябрендә 10 сәгатькә Имәнле-Бортас авылы, Гагарин урамы, 7а й. адресы буенча клуб бинасында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Кече Мәми авылы җирлегендә ***үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын*** билгеләргә.
2. 2025 елның 25 ноябрендә 10 сәгатькә Имәнле-Бортас авылы, Гагарин урамы, 7а й. адресы буенча клуб бинасында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Кече Мәми авылы җирлегендә ***үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын*** билгеләргә.
3. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«2026 елда Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Кече Мәми авыл җирлеге Имәнле-Бортас торак пункты территориясендә даими яшәүче балигъ булган гражданнардан һәм яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме:

- урамнарны яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм алар янындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм

электр энергиясен урнаштыру өчен билгеләнгән башка мәйданчыкларны ремонтлау (шул исәптән светодиодлы урам яктырткычлары, таймерлар, СИП чыбыклары сатып алу);

- су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алу, аны чистарту, су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су башняларын, скважиналарны һәм башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;
- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;
- торак пункт территориясен төзекләндерү;
- каты коммуналь калдыкларны туплау мәйданчыкларын төзү, каты коммуналь калдыкларны җыю өчен контейнерлар сатып алу, рөхсәтсез чүплекләрне бетерү?

«РИЗА» «КАРШЫ»?

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru), мәгълүмат стендларында һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://mmemin-kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча Кайбыч муниципаль районы Кече Мәми авыл җирлегенең рәсми сайтында бастырырга.

5. Әлеге карар рәсми басылып чыккан вакыттан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районының
Кече Мәми авыл җирлеге Башлыгы Е.Н.Алексеева